КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 7 май г.Казань № 671

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 2004 ел, 10 ноябрь, 480 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 14 июнь, 265 нче; 2005 ел, 8 сентябрь, 442 нче; 2006 ел, 30 гыйнвар, 33 нче; 2007 ел, 29 гыйнвар, 22 нче; 2007 ел, 5 март, 70 нче; 2008 ел, 4 февраль, 61 нче; 2009 ел, 9 сентябрь, 628 нче; 2009 ел, 18 декабрь, 860 нчы; 2013 ел, 4 март, 144 нче; 2016 ел, 20 февраль, 106 нчы; 2017 ел, 3 июнь, 335 нче; 2018 ел, 1 сентябрь, 742 нче; 2020 ел, 30 октябрь, 976 нчы; 2021 ел, 21 июль, 630 нчы; 2021 ел, 15 сентябрь, 877 нче; 2021 ел, 30 декабрь, 1355 нче; 2023 ел, 20 февраль, 162 нче; 2023 ел, 21 март, 308 нче; 2023 ел, 3 июнь, 684 нче; 2024 ел, 16 гыйнвар, 10 нчы; 2025 ел, 16 декабрь, 1091 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турындагы нигезләмәдә:

6 пунктның дүртенче абзацында «янгын куркынычсызлыгын,» сүзләреннән соң «гражданнар оборонасын» сүзләрен өстәргә;

24 пунктның уникенче абзацында татар текстында «халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне куркыныч янамый торган районнарга эвакуацияләүгә әзерләү, аларны урнаштыру» сүзләрен «халыкны эвакуацияләүгә әзерләү буенча, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне саклауга әзерләү һәм саклау буенча» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе турындагы нигезләмәдә:

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Комиссиянең төп бурычлары

Комиссиянең төп бурычлары:

гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр эшләү;

гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасына караган идарә органнары һәм көчләр эшчәнлеген координацияләү;

әлеге органнар һәм оешмалар тарафыннан гражданнар оборонасы чаралары үткәрелгәндә федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар эшчәнлеген координацияләү;

гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, шулай ук гадәттән тыш хәлләр аркасында зыян күргән һәм җимерелгән торак йортларны, торак-коммуналь хуҗалык, социаль өлкә объектларын, җитештерү һәм инженерлык инфраструктурасын торгызу һәм төзү өлкәсендә бурычларны хәл иткәндә федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, дәүләт корпорацияләре, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар гамәлләренең килешенгәнлеген тәэмин итү;

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү чараларын оештыруга һәм үткәрүгә гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын җәлеп итү турында мәсьәләләрне карап тикшерү;

гадәттән тыш хәлләр турында халыкка хәбәр итүне һәм мәгълүмат бирүне оештыру турында мәсьәләләрне карап тикшерү.

Башка бурычлар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенә йөкләнергә мөмкин.»;

3 бүлектә:

икенче абзацта «янгын куркынычсызлыгын,» сүзләреннән соң «гражданнар оборонасын» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта татар текстында «тәэмин итү өлкәсендә» сүзләреннән соң «, шулай ук гражданнар оборонасы өлкәсендә» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта татар текстында «тәэмин итүгә» сүзләреннән соң «, шулай ук гражданнар оборонасы чаралары үтәлешен тәэмин итүгә» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Россия Федерациясе дәүләт программаларын эшләүдә катнаша һәм аларны гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр әзерли;»;

алтынчы абзацта «эшләвен» сүзеннән соң «, шулай ук гражданнар оборонасы эшләвен һәм аны камилләштерүне тәэмин итү» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацта татар текстында «өлкәсендә» сүзеннән соң «, шулай ук гражданнар оборонасы өлкәсендә» сүзләрен өстәргә;

сигезенче абзацта «әлеге гадәттән тыш хәлләр» сүзләреннән соң «һәм мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында барлыкка килә торган куркынычлар» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәсьәләләре» 2004 ел, 30 декабрь, 614 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 15 апрель, 187 нче; 2006 ел, 2 август, 396 нчы; 2007 ел, 12 октябрь, 549 нчы; 2009 ел, 2 март, 117 нче; 2009 ел, 21 сентябрь, 657 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 1 июль, 534 нче; 2011 ел, 25 октябрь, 887 нче; 2013 ел, 18 март, 178 нче; 2013 ел, 7 ноябрь, 858 нче; 2014 ел, 7 февраль, 70 нче; 2014 ел, 20 май, 336 нчы; 2014 ел, 10 декабрь, 970 нче; 2015 ел, 5 июнь, 422 нче; 2015 ел, 9 декабрь, 929 нчы; 2016 ел, 15 апрель, 227 нче; 2016 ел, 14 июль, 480 нче; 2016 ел, 27 июль, 517 нче; 2017 ел, 24 октябрь, 805 нче; 2018 ел, 4 июль, 552 нче; 2018 ел, 26 ноябрь, 1052 нче; 2018 ел, 18 декабрь, 1160 нчы; 2019 ел, 21 март, 197 нче; 2019 ел, 9 декабрь, 1130 нчы; 2020 ел, 20 март, 211 нче; 2020 ел, 10 апрель, 269 нчы; 2020 ел, 17 апрель, 302 нче; 2021 ел, 23 август, 770 нче; 2021 ел, 3 ноябрь, 1044 нче; 2022 ел, 26 гыйнвар, 55 нче; 2022 ел, 21 ноябрь, 1250 нче; 2023 ел, 14 март, 247 нче; 2023 ел, 3 июнь, 686 нчы; 2023 ел, 28 ноябрь, 1527 нче; 2024 ел, 21 август, 678 нче; 2024 ел, 6 декабрь, 1111 нче; 2025 ел, 16 апрель, 234 нче; 2025 ел, 4 июнь, 408 нче; 2026 ел, 10 февраль, 89 нчы; 2026 ел, 4 март, 162 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1 пунктта:

4.1.22 пунктның сигезенче абзацында татар текстында «халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне куркыныч янамый торган районнарга эвакуацияләүгә әзерләү, аларны урнаштыру» сүзләрен «халыкны эвакуацияләүгә әзерләү буенча, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне саклауга әзерләү һәм саклау буенча» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 4.1.31 пунктча өстәргә:

«4.1.31. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештереп, ведомство бүләкләрен гамәлгә куя һәм алар белән Министрлык хезмәткәрләрен, шулай ук Министрлыкка йөкләнгән бурычларны хәл итүдә ярдәм күрсәтүче башка затларны бүләкли.»;

5.4 пунктның егерме беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклауны, янгын куркынычсызлыгын, су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итүгә, шулай ук гражданнар оборонасы бурычларын хәл итүгә өлеш керткән гражданнарны ведомство бүләкләре һәм бүләкләүнең башка төрләре белән бүләкләү турында карарлар кабул итә.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын гражданнар оборонасы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә әзерләүне оештыру турында» 2016 ел, 20 май, 331 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 7 июль, 463 нче; 2021 ел, 6 апрель, 216 нчы; 2023 ел, 11 июль, 810 нчы карарлары

белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), преамбуладагы «хәрби конфликтлар булганда яки бу конфликтлар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен булдыру һәм аларны әзер килеш тоту турында» 2017 ел, 15 июль, 496 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 11 июль, 810 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «хәрби конфликтлар вакытында яисә бу конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр булганда» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә гражданнар оборонасы көчләре турындагы нигезләмәдә:

3 бүлектә:

җиденче абзацта «хәрби конфликтлар вакытында яисә бу конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр булганда халык өчен куркынычлар барлыкка килү» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында килеп чыга торган куркынычлар» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта «хәрби конфликтлар вакытында яисә бу конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр булганда халык өчен куркынычлар барлыкка килү» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында килеп чыга торган куркынычлар» сүзләренә алмаштырырга;

унберенче абзацта «хәрби конфликтлар вакытында яисә бу конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр булганда» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында килеп чыга торган куркынычлар нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

унөченче абзацта «хәрби конфликтлар барганда яисә бу конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр булганда» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында килеп чыга торган куркынычлар нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы эвакуация комиссиясен төзү турында» 2020 ел, 24 июль, 620 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 4 февраль, 55 нче; 2021 ел, 30 декабрь, 1367 нче; 2023 ел, 20 март, 296 нчы; 2023 ел, 11 июль, 810 нчы; 2024 ел, 20 май, 342 нче; 2025 ел, 28 март, 178 нче; 2026 ел, 17 март, 223 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне куркыныч янамый торган районнарга эвакуацияләүне планлаштыру, әзерләү һәм үткәрү эшләрен оештыру» сүзләрен «халыкны эвакуацияләүгә әзерләү, матди һәм мәдәни кыйммәт-

ләрне саклауга әзерләү һәм саклау чараларын планлаштыру» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «Татарстан Республикасы халыкын, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне куркыныч янамый торган районнарга эвакуацияләү» сүзләрен «Татарстан Республикасы халкын эвакуацияләүгә әзерләү, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне саклауга әзерләү һәм саклау» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәдә:

1.2 пунктта «тыныч вакытта, гражданнар оборонасы системасын билгеләнгән әзерлек дәрәҗәсенә күчергәндә һәм сугыш вакытында эвакуация чараларын турыдан-туры планлаштыру, әзерләү һәм үткәрү буенча» сүзләрен «халыкны эвакуацияләүгә әзерләү, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне саклауга әзерләү һәм саклау чараларын планлаштыру буенча» сүзләренә алмаштырырга;

1.7 пунктның дүртенче абзацында «куркыныч булмаган районнарда» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.9 пунктта «тыныч вакытта һәм сугыш вакытында» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.2 пунктта:

«а» пунктчасының өченче абзацында «куркыныч булмаган районда» сүзләрен төшереп калдырырга;

«б» пунктчасының сигезенче абзацында «куркыныч булмаган районнарда» сүзләрен төшереп калдырырга;

«в» пунктчасында:

дүртенче абзацта «һәм аны куркыныч булмаган районнарга җибәрү» сүзләрен төшереп калдырырга;

сигезенче абзацта «сугыш вакытына» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацта «куркыныч булмаган районнарда» сүзләрен төшереп калдырырга.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасын һәм халыкны саклауны күзәтү һәм лаборатория тикшерүендә тоту челтәренең Татарстан Республикасы территориаль ярдәмче челтәре турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 ел, 28 сентябрь, 879 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 5 декабрь, 1280 нче; 2023 ел, 13 май, 590 нчы; 2024 ел, 15 ноябрь, 1010 нчы; 2026 ел, 23 март, 260 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданнар оборонасын һәм халыкны саклауны күзәтү һәм лаборатория тикшерүендә тоту челтәренең Татарстан Республикасы территориаль ярдәмче челтәре турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктта «хәрби конфликтлар вакытында яисә бу конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр булганда» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктның бишенче абзацында «хәрби конфликтлар вакытында яисә бу конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән

тыш хәлләр булганда» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында» сүзләренә алмаштырырга.

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең бердәм кизү-диспетчерлык хезмәтләре тарафыннан Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасындагы көндәлек идарә органнары һәм гражданнар оборонасы белән идарә итү органнары эшчәнлеген координацияләү, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, республика башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның мәгълүмати хезмәттәшлеген оештыру муниципаль дәрәҗәдә тәэмин ителү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 21 февраль, 147 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 11 июль, 810 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең бердәм кизү-диспетчерлык хезмәтләре тарафыннан Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасындагы көндәлек идарә органнары һәм гражданнар оборонасы белән идарә итү органнары эшчәнлеген координацияләү, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, республика башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның мәгълүмати хезмәттәшлеген оештыру муниципаль дәрәҗәдә тәэмин ителү тәртибенә, 5 пунктның «а» пунктчасындагы сигезенче абзацында «хәрби конфликтлар вакытында яисә бу конфликтлар нәтиҗәсендә» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасы буенча республика дәрәҗәсендәге чараларны үтәүне тәэмин итә торган республика башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары һәм оешмалар исемлеген раслау турында» 2023 ел, 6 ноябрь, 1426 нчы карары белән расланган Гражданнар оборонасы буенча республика дәрәҗәсендәге чараларны үтәүне тәэмин итә торган республика башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары һәм оешмалар исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлекнең исемендә «хәрби конфликтлар вакытында яисә бу конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр булганда» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлектә:

исемендә «Халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне куркыныч янамый торган районнарга эвакуацияләү» сүзләрен «Халыкны эвакуацияләү, матди һәм мәдәни хәзинәләрне саклау» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктның 3 графасындагы беренче абзацында татар текстында «эвакуация» сүзен «халыкны эвакуацияләүне, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне саклауны» сүзләренә алмаштырырга;

4 бүлекнең 4.1 пунктындагы 3 графасының икенче абзацында «сугыш вакытында» сүзләрен төшереп калдырырга;

6 бүлектә:

исемендә «хәрби конфликтлар вакытында яисә бу конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр булганда халык өчен куркынычлар барлыкка килү» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында килеп чыга торган куркынычлар» сүзләренә алмаштырырга;

6.1 пунктның 3 графасындагы беренче абзацны татар текстында түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «гражданнар оборонасының кирәкле көчләрен һәм чараларын булдыру, җиһазландыру һәм әзерләү, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының кирәкле көчләрен җиһазландыру һәм әзерләү, шулай ук аларның гамәлләрен планлаштыру»;

7 бүлектә:

исемендә «хәрби конфликтлар вакытында яисә бу конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр булганда» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында килеп чыга торган куркынычлар нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

7.2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

7.4 пунктның 3 графасында «хәрби конфликтлар вакытында яисә бу конфликтлар нәтиҗәсендә» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында килеп чыга торган куркынычлар нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

8 бүлектә:

исемендә «хәрби конфликтлар вакытында яисә бу конфликтлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында барлыкка килгән куркынычлар нәтиҗәсендә килеп чыккан» сүзләренә алмаштырырга;

8.2 пунктның 3 графасында:

беренче абзацта «сугыш вакытында» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «, сугыш вакытында» сүзләрен төшереп калдырырга;

10 бүлекнең исемендә «хәрби конфликтлар вакытында яисә бу конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр булганда» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында килеп чыга торган куркынычлар нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

13 бүлектә:

исемендә «хәрби конфликтлар вакытында яисә бу конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр булганда» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында килеп чыга торган куркынычлар булганда» сүзләренә алмаштырырга;

13.1 пунктның 3 графасындагы беренче абзацында «тыныч вакытта һәм сугыш вакытында» сүзләрен төшереп калдырырга;

13.4 пунктның 3 графасында «тыныч вакытта һәм сугыш вакытында» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин